**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 18 мартындагы 850 номерлы карары**

**Казан шәһәрендә «Рамазан Фест» мәдәни-массакүләм чарасын үткәрү һәм чараны әзерләү һәм уздыру чорында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында**

«Рамазан Фест» мәдәни-массакүләм чарасын әзерләү һәм уздыру чорында куркынычсызлыкны тәэмин итү максатыннан, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. ихтыяҗ булганда, түбәндәге участокларда транспорт чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен чикләүне кертергә:

1.1.1. 2026 елның 19 мартында 18:00 сәгатьтән 2026 елның 20 мартында 22:00 сәгатькә кадәр Шиһабетдин Мәрҗани урамында, Татарстан урамыннан Фатыйх Кәрим урамына кадәрге участокта, һәм Каюм Насыйри урамында, Татарстан урамыннан Зәйни Солтан урамына кадәрге участокта;

1.1.2. 2026 елның 20 мартында 18:00 сәгатьтән 2026 елның 21 мартында 23:59 сәгатькә кадәр «Казан» халыкара ат спорты комплексы янындагы парковка зонасының барлык территориясендә, шул исәптән Альберт Камалиев проспектыннан Альберт Камалиев проспектындагы 27р номерлы йортка кадәр автомобиль юлы буйлап;

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.2.1. вакытлыча юл билгеләрен урнаштыру һәм гамәлдәге юл билгеләрен каплау буенча чаралар оештырырга;

1.2.2. транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл

хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (А.М.Шайнуров) Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе (А.И.Салихов) һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Совет районы администрациясе (Р.Р.Фәтхетдинов) белән берлектә юлларны йөк техникасы яки таранга каршы блоклар белән ябу эшен оештырырга;

1.4. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм**:

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участогында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) урам-юл челтәренең күрсәтелгән участогында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләүне кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**